ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22 октябрь, 2015 ел № 2/11

Физик затлар мөлкәтенә
салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, Татарстан Республикасының 2014 елның 30 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр хакыннан чыгып билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәй датасын билгеләү турында» 82-ЗРТ санлы Законы, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә, салым салу объектларының кадастр хакыннан чыгып, мәҗбүри түләнергә тиешле салымны билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) 0,1 процент:

- гаражлар һәм машина урыннары;

- һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм ярдәмче, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык алып бару яки шәхси торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары мөнәсәбәтендә;

2) 0,2 процент:

- фатирлар;

- бүлмәләр мөнәсәбәтендә;

3) 0,3 процент:

- торак йортлар;

- әгәр объектларның проект билгеләнеше йорт булган очракта, тәмамланмаган төзелеш объектлары;

- составына бер генә торак бина (торак йорт) булса да кергән бердәм күчемсез комплекслар мөнәсәбәтендә;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 маддәсе 7 пункты нигезендә билгеләнгән исемлеккә кергән салым салу объектлары һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 маддәсе 10 пункты икенче абзацы белән каралган салым салу объектлары мөнәсәбәтендә

2015 елда 1,2 процент, 2016 елда 1,5 процент, 2017 елда 1,8 процент, 2018 елда һәм аннан соң килгән елларда 2,0 процент;

5) 2,0 процент һәркайсының кадастр хакы 300 млн. сумнан арткан салым салу объектлары мөнәсәбәтендә;

6) 0,5 процент башка салым салу объектлары мөнәсәбәтендә.

3. Күпфатирлы бер катлы ике фатирдан торган торак йорттагы фатир хуҗаларына исәпләп чыгарылган салым суммасын әлеге фатирның утыз квадрат метр гомуми мәйданы кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнгән суммасына кимету рәвешендә ташлама бирергә.

Фатир гомуми өлеш милегендә булган очракта, ташлама суммасы өлеш милегенең һәрбер катнашучысына әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ исәпләнә.

Фатир гомуми уртак милектә булган очракта, ташлама суммасы уртак милекнең һәрбер катнашучысына тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт белән исәпләнгән ташлама суммасы исәпләп чыгарылган салым суммасыннан артырга тиеш түгел.

4. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәр өч яки аннан да күбрәк баласы булган салым түләүчеләрне;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән салым түләүчеләрнең балаларын.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләре мөнәсәбәтендә бирелә:

1) гомуми мәйданы 100 квадрат метрдан артмаган, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге 403 маддәсе 3, 4, 5 пунктлары белән каралган мәйдан буенча стандарт тотып калуларны исәпкә алып, фатир (бүлмә) яки торак йорт;

2) мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган гараж яки машина урыны.

Салым ташламасы гаиләгә туры килгән һәрбер төрнең бер салым салу объекты мөнәсәбәтендә салым түләүченең сайлавы буенча бирелә.

Салым ташламасы Яр Чаллы шәһәре территориясендә яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүченең милегендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмаган салым салу объекты мөнәсәбәтендә салым түләүче тарафыннан түләнергә салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым ташламасына хокуклы зат салым органына ташлама бирү турында гариза һәм әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән, салым ташламасына хокукы булуны раслаучы документларны тапшыра.

Салым органына сайлап алынган салым ташламасы бирелә торган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым чоры булган елның 1 ноябренә кадәр (шул вакыттан күрсәтелгән объектлар мөнәсәбәтендә салым ташламасы кулланыла) тапшырыла.

5. Шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым ставкалары турында» 34/4 санлы Карары («Шәһри Чаллы» газетасының 2014 елның 26 ноябрендәге 88 санында, «Челнинские известия» газетасының 2014 елның 26 ноябрендәге 88 санында басылган) үз көчен югалткан дип танырга.

**6.** Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көннән соң бер ай үткәч үз көченә керә.

Әлеге Карар 2015 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш һәм бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
2/11 нче Карарына
кушымта
22 октябрь, 2015 ел

18 яшькә кадәр өч яки аннан да күбрәк баласы булган салым түләүчеләргә ташлама бирү өчен кирәкле документлар исемлеге

1) күп балалы гаилә таныклыгы;

2) гариза бирүченең паспорт күчермәсе (2, 3, 5, 14, 16, 17 битләр);

3) икенче ата-ананың паспорт күчермәсе (2, 3, 5, 14, 16, 17 битләр);

4) балаларның туу турында таныклыклары күчермәсе, шулай ук 14 яшькә җиткән балаларның паспорт күчермәләре (2, 3, 5 битләр);

5) баланы уллыкка алуны билгеләү турында суд карарының күчермәсе (баланың туу турында таныклыгында уллыкка алучылар ата-ана сыйфатында язылган очраклардан тыш);

6) опека һәм попечительлек органының опекун яисә попечитель билгеләү турында акты күчермәсе (опека яки попечительлек билгеләнгән очракта);

7) опеканы яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турында килешү күчермәсе (опека яки попечительлек килешү буенча гамәлгә ашырылганда);

8) өйләнешү турында таныклык күчермәсе;

9) тору урыныннан белешмә.